КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 16 июль г.Казань № 595

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 22 февраль, 112 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 22 февраль, 112 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы казнасын тәшкил иткән объектларны (финанс булмаган активларны) яңадан бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Объектларны (финанс булмаган активларны) (җир кишәрлекләреннән тыш) яңадан бәяләү Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә төзелгән Объектларның (финанс булмаган активларның) базар кыйммәтен бәяләү турындагы хисап (ул булганда) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Базар кыйммәтен бәяләү турындагы хисап булмаган очракта:

1) Күчмә мөлкәткә кергән Объектларны (финанс булмаган активларны) (алга таба – күчмә мөлкәт) яңадан бәяләү Объектның (финанс булмаган активның) баланс кыйммәтен һәм амортизация суммасын үзгәртмичә башкарыла. Шул ук вакытта баланс кыйммәте билгеләнмәгән күчмә мөлкәтне яңадан бәяләү бюджет исәбендә

беренчел кыйммәтне шартлы бәяләүдә: бер объект, бер сум дип күрсәтеп гамәлгә ашырыла.

2) Күчемсез мөлкәткә кергән Объектларны (финанс булмаган активларны) (җир кишәрлекләреннән тыш) (алга таба – күчемсез мөлкәт объектлары) яңадан бәяләү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

эксплуатациядә 20 елдан артык булган яисә эксплуатациягә кертү елы билгеләнмәгән күчемсез мөлкәт объектларын яңадан бәяләү күчемсез мөлкәт объектының яңадан бәяләү көненә кадастр кыйммәтен билгеләү юлы белән башкарыла. Җыелган амортизация суммасы аерым исәпләнә;

эксплуатациядә 20 елдан азрак булган яисә кадастр исәбенә куелмаган һәм кадастр кыйммәте булмаган күчемсез мөлкәт объектларын яңадан бәяләү баланс кыйммәтен һәм амортизация суммасын үзгәртмичә башкарыла. Шул ук вакытта баланс кыйммәте билгеләнмәгән күчемсез мөлкәтне яңадан бәяләү бюджет исәбендә беренчел кыйммәтне шартлы бәяләүдә: бер объект, бер сум дип күрсәтеп гамәлгә ашырыла.»;

5 нче пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин